**СОВЕТ**
**ПЕТРОПАВЛОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Ленина, д. 33
с. Слобода Петропавловская,423198

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ПЕТРОПАВЕЛ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Ленин урамы, 33
Петропавловка бистәсе авылы ,423198

тел.: (8-4348) 3-35-41, факс: (8-4348) 3-35-18.Ppav.Nsm@tatar.ru

КАРАР КАРАР

2019 елның 29 октябре № 1

"Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавловск авылҗирлегендәгражданнарныңүзарасалымакчаларынкертүһәмалардан файдаланумәсьәләсебуенчагражданнарҗыенынбилгеләүтурында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статья лары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Петропавловское авылҗирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Петропавловск авыл җирлеге башлыгы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавловск авыл җирлегенең Петропавловск авылында Ленин урамы буенча 79-101 һәм 54-88, Яр буе урамы буенча 31-49, Совет урамы буенча 38-47 нче йортларда яшәүче гражданнарның үзара салымакчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 10 ноябрь көнне сәгать 11.00 Петропавловск авылында Ленин урамы, 70 йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавловск авыл җирлегенең Петропавловск авылында Ленин урамы буенча 23-77 һәм 18-48, Яр буе урамы буенча 1-30, Совет урамы буенча 15-36, Заливная, Петропавловск авыл җирлеге Звездная урамнары буенча йортларда яшәүче гражданнарның үзара салымакчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын Петропавловск мәдәният йортында 10 ноябрь көнне сәгать 14.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавловск авыл җирлегенең Петропавловск авылында Совет урамы буенча 1-7 авылыннан; Түбән урамы буенча 9-17 йорттан; Полыновская урамы, Краснореченская урамыйортларында яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын 2019 елның 16 ноябрендә сәгать 10.00 сәгатькә Түбән урам буенча 16 нчы йорт янында билгеләргә.

буенча халык җыенының өченче этабын 2019 елның 16 ноябрендә сәгать 10.00 сәгатькә Түбән урам буенча 16 нчы йорт янында билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавловск авыл җирлегенең Петропавловск авылында Ленин урамы буенча 3-21 нче һәм 2-14 нче, Түбән урам буенча 1-8 нче, Совет урамы буенча 8-13 нче, Заозерная урамында Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавловск авыл җирлегенең үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын Петропавел төп гомуми белем бирү мәктәбендә 2019 елның 16 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Халык җыенын үткәрү өчен Петропавел Бистәсе халкы исемлеген бүлеп сайлау тәртибе территориаль бүленеш буенча башкарылырга тиеш.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавловск авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2020 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Петропавловск авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары,Чернобыль АЭСдәге һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы, 1 төркеми нвалидлар, картлар һәм инвалидлар интернат йортында яшәүче гражданнардан тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- юлларны кышкы чорда кардан чистарту;
- җәйге чорда территориядәге чүп үләннәрне чабу (ягулык-майлау материаллары сатыпалу, эшләр һәм килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
- Совет урамы буенча су белән тәэминитү челтәрләрен ремонтлау, реконструкцияләү (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, эшләр өчен түләү) ;
- су башнясы өчен автоматика сатыпалу (җиһазлар, запас частьләр сатыпалу, килешү буенча түләү);

"РИЗА" "КАРШЫ"

8. Әлеге карарны «Интернет"мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игъланитәргә).

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Петропавловка авыл җирлеге башлыгы Д. С. Никитин

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ "ПЕТРОПАВЛОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ" НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
р 05-12010/14
СОВЕТ ПЕТРОПАВЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ